СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 6-13 от «23» марта 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма, Дүсмәт, Көмешкүл, Көек-Ерыкса, Келәүш, Кече Кирмән,Түбән Сон, Олыяз, Урта Кирмән, Тауиле, Уразбахты, Урманчы, Усали, Яке, Сон, Шәдче, Шәмәк авыл җирлекләренең генераль планын әзерләү зарурлыгы булмау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма, Дүсмәт, Көмешкүл, Көек-Ерыкса, Келәүш, Кече Кирмән,Түбән Сон, Олыяз, Урта Кирмән, Уразбахты, Усали, Яке, Сон, Шәдче, Шәмәк авыл җирлекләре территориясеннән файдалануны үзгәртү күздә тотылмау, әлеге территорияләрдә Татарстан Республикасының һәм Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш һәм территориаль планлаштыру схемалары белән расланган комплекслы программасы булмау һәм социаль-икътисадый үсеш һәм территориаль планлаштыру схемаларында федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру каралмаган булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы

к а р а р к а б у л и т т е:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма, Дүсмәт, Көмешкүл, Көек-Ерыкса, Келәүш, Кече Кирмән,Түбән Сон, Олыяз, Урта Кирмән, Тауиле, Уразбахты, Урманчы, Усали, Яке, Сон, Шәдче, Шәмәк авыл җирлекләренең генераль планын әзерләү зарурлыгы булмауны танырга.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының (mamadysh.tatarstan.ru) рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының җирле үзидарә, аграр сәясәт, җирдән файдалану һәм экология буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П. Иванов

000009